МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

18.07.2017 Казан шәһ. № 231

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәренең ялланган вәкиленә бер генә кеше башкара торган башкарма орган сыйфатында коммерция эшчәнлеге алып бармаган оешмалар белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашырга яисә аларга идарәнең коллегиаль органы составына керергә рөхсәт бирү тәртибе турында

«Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ Федераль законының 17нче маддәсе 1нче өлешенең 3нче пунктына ярашлы рәвештә боерам:

1. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәренең ялланган вәкиленә бер генә кеше башкара торган башкарма орган сыйфатында коммерция эшчәнлеге алып бармаган оешмалар белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашырга яисә аларга идарәнең коллегиаль органы составына керергә рөхсәт бирү тәртибен расларга (алда – Тәртип).

2. Әлеге боерыкны контрольгә алуны үземдә калдырам.

**Министр** **А.А.Здунов**

Татарстан Республикасы
икътисад министры
раслады 18.07.2017 №231

Тәртип

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәренең ялланган вәкиленә бер генә кеше башкара торган башкарма орган сыйфатында коммерция эшчәнлеге алып бармаган оешмалар белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашырга яисә аларга идарәнең коллегиаль органы составына керергә рөхсәт бирү

1. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәренең ялланган вәкиленә бер генә кеше башкара торган башкарма орган сыйфатында коммерция эшчәнлеге алып бармаган оешмалар белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашырга яисә аларга идарәнең коллегиаль органы составына керергә рөхсәт бирү тәртибе (алда – Тәртип) «Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ Федераль законының 17нче маддәсе 1нче өлешенең 3нче пунктына ярашлы рәвештә эшләнгән

Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәренең ялланган вәкиленә Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында (алда – гражданлык хезмәткәрләре) җәмәгать оешмалары, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары, бакчачылык, дача куллану кооперативлары, күчмәс милек җәмгыятьләре (алда - коммерция эшчәнлеге алып бармаган оешма) белән идарә иткәндә бер кеше башкара торган башкарма власть органы сыйфатында яисә аларның коллегиаль идарә органнары составында бушлай нигездә катнашырга рөхсәт бирү процедурасын карый

Әлеге Тәртип ялланган вәкиле Татарстан Республикасы икътисад министры булган Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында Татарстан Республикасы гражданлык хезмәткәрләренә кагыла.

2. Бер кеше башкара торган башкарма орган сыйфатында коммерция эшчәнлеге алып бармаган оешмалар идарәсендә бушлай нигездә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт турында гариза (алда - Гариза) гражданлык хезмәткәре тарафыннан әлеге Тәртипнең 1нче Кушымтасына ярашлы рәвештә язма формада төзелә.

3. Гражданлык хезмәткәре коррупцион һәм башка хокук бозулар профилактикасы буенча эш өчен җаваплы затка гариза бирә (алда – Җаваплы зат).

4. Җаваплы зат Гаризаны килгән көнне үк әлеге Тәртипнең 2нче кушымтасына ярашлы формада Журналда терки.

5. Җаваплы зат Гаризаны алдан карый һәм нәтиҗәләргә карап җавап әзерли

Гаризаны алдан карау барышында Җаваплы зат Гариза биргән гражданлык хезмәткәреннән коммерция эшчәнлеге алып бармаган оешма белән идарә итүдә планлаштырылган катнашу буенча функцияләрне билгеләүче язма аңлатмаларны һәм документларны соратып алу хокукына ия.

Чыгарылган нәтиҗәдә гражданлык хезмәткәренә бер кеше башкара торган башкарма орган сыйфатында коммерция эшчәнлеге алып бармаган оешмалар идарәсендә бушлай нигездә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәтне бирү һәм бирмәү турында тәкъдим булырга тиеш

6. Гариза теркәлгән көннән алып биш эш көннән дә соңга калмыйча Җаваплы зат нәтиҗәсе беркетелгән Гаризаны һәм башка материалларны (булган очракта) Татарстан Республикасы икътисад министрына (аның вазифасын башкаручыга) гражданлык хезмәткәренә бер кеше башкара торган башкарма орган сыйфатында коммерция эшчәнлеге алып бармаган оешмалар идарәсендә бушлай нигездә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәтне бирү һәм бирмәү турында карар чыгару өчен бирә.

Татарстан Республикасы икътисад министры ( аның вазифасын башкаручы зат) Гаризаны алган көннән алып ике эш көне эчендә карар чыгара.

7. Җаваплы зат Татарстан Республикасы икътисад министры (аның вазифасын башкаручы) карар чыгарган көннән алып ике эш көне эчендә гражданлык хезмәткәренә Гаризаны карау нәтиҗәләре турында хәбәр итә һәм Татарстан Республикасы икътисад министры резолюциясе белән Гариза күчермәсен кадрлар бүлегенең расланган мөһере белән аңа тапшыра. Татарстан Республикасы икътисад министры резолюциясе белән Гариза оригиналы гражданлык хезмәткәренең шәхси эшенә беркетелә.

___________________________

Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәренең ялланган вәкиленә Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында бер кеше башкара торган башкарма орган сыйфатында коммерция эшчәнлеге алып бармаган оешмалар идарәсендә бушлай нигездә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органы составына керүгә рөхсәт Тәртибенә 1нче Кушымта

Татарстан Республикасы Икътисад министрына

___________________________________

___________________________________

(Ф.И.Осы, башкарган вазифасы һәм структур

___________________________________

бүлекчә, яшәү урыны адресы

___________________________________

телефон номеры)

Гариза
Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәренең ялланган вәкиленә Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында бер кеше башкара торган башкарма орган сыйфатында коммерция эшчәнлеге алып бармаган оешмалар идарәсендә бушлай нигездә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт бирү турында

Миңа идарәдә катнашуга, идарәнең коллегиаль органы составына керүгә рөхсәт бирүегезне сорыйм (кирәклесенең астына сызарга)______________________________

(җәмәгать оешмасы,

___________________________________________________________________________

торак, торак-төзелеш, гараж кооперативы, бакчачылык оешмалары,

___________________________________________________________________________

дача куллану кооперативы, күчмәс милек җәмгыяте исемнәре)

бушлай нигездә

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

(бер кеше башкара торган башкарма орган яисә идарәнең коллегиаль органы исеме)

| | | |
|---|---|---|
| ________________ | ________________________ | ____________________ |
| (дата) | (имза) | (фамилия, инициаллар) |

Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәренең ялланган вәкиленә Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында бер кеше башкара торган башкарма орган сыйфатында коммерция эшчәнлеге алып бармаган оешмалар идарәсендә бушлай нигездә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органы составына керүгә рөхсәт Тәртибенә 2нче Кушымта

ЖУРНАЛ
Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәренең ялланган вәкиленә Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгында бер кеше башкара торган башкарма орган сыйфатында коммерция эшчәнлеге алып бармаган оешмалар идарәсендә бушлай нигездә катнашуга яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә рөхсәт бирү турында гаризаларны теркәү

| № п/п | Дата | Ф.И.О., үтенеч бирүченең вазифасы | Үтенеч бирүче имзасы | Теркәүче Ф.И.Осы | Теркәүче имзасы |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |